КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 июль г.Казань № 828

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль һәм республика программаларын тормышка ашыруда катнашучы социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның республика реестры турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1035 нче карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар – ярдәм алучылар республика реестры турында» 2012 ел, 16 март, 218 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 сентябрь, 668 нче, 2015 ел, 5 июнь, 423 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар - ярдәм алучылар турында белешмәләр

______________________________________________

(ярдәм күрсәтүче республика башкарма хакимияте органы,
муниципаль районның (шәһәр округының) җирле үзидарә органы исеме)»;

әлеге карар белән расланган Ярдәм алу турындагы мәгълүматны социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар – ярдәм алучылар республика реестрына кертү өчен бирү тәртибенең нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2012 ел, 13 март, 218 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 20 сентябрь, 668 нче
карары редакциясендә)».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 7 апрель, 218 нче; 2018 ел, 14 май, 358 нче; 2019 ел, 15 апрель, 293 нче; 2020 ел, 11 апрель, 274 нче, 2023 ел, 03 апрель, 387 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктның җиденче абзацында «башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, СЮ КБО һәм социаль өлкәдә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы СЮ КБО халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет чараларыннан файдалана алуын киңәйтү буенча башка кызыксынган оешмалар эшчәнлегенә ярдәм итү механизмнарын булдыру.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 гыйнвар, 78 нче, 2023 ел, 22 март, 324 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында нигезләмәгә, 2.2 пунктның «ж» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның республика реестры турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1035 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин